Татарстан Республикасы
Мәгариф һәм фән министрлыгы

# Татар әдәбиятыннан гомуми белем бирүнең дәүләт стандарты

Казан
2008

Эчтәлек


1. Гомуми белем бирү программаларының структурасына таләпләр 3—8

2. Белем бирү нәтиҗәләренә (гомуми белем бирү программаларын үзләштерү нәтиҗәләренә) таләпләр 8—14

3. Гомуми белем бирүнең эчтәлеге (фундаменталь төш) 14—20

3.1. Гомуми башлангыч белем бирү мәктәбе (1 нче баскыч – I–IV сыйныфлар)

3.2. Гомуми төп белем бирү мәктәбе (2 нче баскыч – V–IX сыйныфлар)

3.3. Гомуми урта (тулы) белем бирү мәктәбе (3 нче баскыч – X–XI сыйныфлар)




# 1. Гомуми белем бирү программаларының структурасына таләпләр

Татар әдәбиятыннан гомуми белем бирүнең дәүләт стандарты түбәндәге хокукый-норматив актларга нигезләнеп эшләнде:

– Россия Федерациясенең «Мәгариф турында»гы Законы (7 нче маддә);

– Россия Федерациясе хөкүмәте раслаган (2001 ел, 29 декабрь, № 1756) «Россия мәгарифен яңарту Концепциясе»;

– Татарстан Республикасының «Мәгариф турында»гы Законы (7 нче маддә);

– «Татарстан Республикасы дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасында башка телләр турында» Татарстан Республикасы Законы (9 нчы маддә).

Татар әдәбиятыннан гомуми белем бирүнең дәүләт стандарты белем эчтәлеген заман таләпләренә туры китереп яңарту, аның сыйфатын һәм нәтиҗәлелеген күтәрү бурычларын хәл итү максатында төзелде. Ул һәр баланың татар әдәбиятыннан яхшы сыйфатлы белем алуга хокукын гарантияли, һәр укучыга тигез мөмкинлекләр тудыра, гомуми белем бирүнең төрле баскычларындагы укыту программаларының бәйләнешен булдыра, укучыларның психик һәм физик сәламәтлеген саклый, артык эш күләменнән азат итә, укучыларны һәм укытучыларны социаль яклауны тәэмин итә.

Стандарт нигезендә татар әдәбиятыннан белем күләме билгеләнә, гомуми башлангыч, гомуми төп һәм гомуми урта (тулы) белем программалары, укыту-методик комплектлар эшләнә, гомуми белем бирү учреждениеләренең укыту планы төзелә.

Татар теленнән һәм татар әдәбиятыннан гомуми белем бирүнең дәүләт стандарты Татарстан Республикасындагы дәүләт аккредитациясенә ия булган барлык дәүләти, муниципаль һәм дәүләти булмаган гомуми белем бирү учреждениеләре өчен мәҗбүри. Ул төзеләчәк программалар өчен җирлек булып тора.

Программаларга әдәби әсәрләрне сайлап алуның төп критерийлары түбәндәгеләр: югары сәнгать әсәре; гуманистик юнәлешле булуы; укучыга уңай тәэсир итүе; укучының үсеш һәм яшь үзенчәлекләренә туры килү; тарихи-мәдәни традицияләрне, туган илебез мәгарифенең бай тәҗрибәсен чагылдыруы.

Укыту программалары, дәреслекләр, методик кулланмалар эшләгәндә авторларга түбәндәгеләр рөхсәт ителә:

- гомуми белем бирү баскычларының бәйләнешен саклаган хәлдә дидактик берәмлекләрнең исемлеген киңәйтү;
- дидактик берәмлекләрне конкретлаштыру һәм детальләштерү;
- өйрәнәчәк материалның логик бәйләнешле һәм педагогик нигезләнгән тәртибен билгеләү.

Татар әдәбиятыннан гомуми белем бирү программалары өч баскычка бүленә. Аларның һәрберсе билгеле бер максатта төзелә, белем бирүнең мәҗбүри минимумына нигезләнә.

# 1 баскыч

**Әдәбияттан гомуми башлангыч белем бирү (1–4 сыйныфлар) баскычының максатлары:**

- татар әдәбияты хакында беренчел күзаллау булдыру;
- әдәби әсәрләрне дөрес, сәнгатьле, тиз укырга һәм аңларга өйрәтү;
- әдәби текст белән эшләү, текст эчтәлеген үз сүзләре белән сөйләү күнекмәсен камилләштерү;
- мөстәкыйль рәвештә әсәрләрне укырга һәм үзләштерергә күнектерү, татар әдәбиятына һәм башка халык әдәбиятларына хөрмәт, китапка кызыксыну булдыру;
- белемгә омтылыш тәрбияләү, укучының иҗади, логик фикерләвен, хәтерен, эстетик зәвыген үстерү, үз-үзен тәрбияләвенә ирешү.

### Әдәбияттан гомуми башлангыч белем бирү (1–4 сыйныфлар) баскычында белем эчтәлегенең мәҗбүри минимумы

**Уку эшчәнлеге**. Әдәби текстны аңлап, дөрес, йөгерек һәм сәнгатьле уку. Уку төрләре (йөгерек, сайлап, аңлатмалы, эчтән, бергәләп) белән танышу. Уку максатларына төшенү. Әдәби әйтелеш нормаларын саклап, дөрес интонация һәм басым белән кычкырып уку.

Сәнгатьчә эшләнеше камил, аңлау–төшенү өчен авыр булмаган, мавыктыргыч һәм гомумкешелек кыйммәтләренә уңай мөнәсәбәт булдырырлык әсәрләр сайлана. Алар арасында әдәби һәм фәнни–популяр әсәрләр, татар халык авыз иҗаты әсәрләре, дөнья балалар әдәбияты классиклары әсәрләре, төрле энциклопедияләрдә, белешмә-сүзлекләрдә һәм балалар вакытлы матбугатында басылган материаллар булырга мөмкин. Балаларга уку өчен тәкъдим ителгән әсәрләрнең төп темалары: туган тел, табигать, хезмәт, балалар тормышы, кешеләрнең үзара мөнәсәбәтләре, гаилә, сәламәтлек саклау, яхшылык һәм яманлык.

**Тыңлау**. Төрле жанрдагы әдәби әсәрләрне тыңлап, аңлы кабул итү. Тыңлаган әсәрнең төп эчтәлеген аңлау һәм ул ясаган эмоциональ тәэсирне аңлатып бирә алу.

**Сөйләм.** Текст эчтәлегенә бәйле сораулар һәм җаваплар бирә белү. Укыганны яки ишеткәнне (укытучы укыганны тыңлап) кабатлап сөйләү. Әсәр турында фикер алышуда катнашу, әңгәмә кора белү. Әсәрнең геройлары, вакыйгалары турында монологик сөйләм төзү; текстны план буенча сөйләү. Үз фикерен дәлилли, моның өчен башка чыганаклардан мисаллар китерә белү. Аралашу (коммуникатив) культурасын үзләштерү. Бирелгән темага (үзе, әти-әнисе, гаиләсе, иптәшләре, табигать һәм тереклек) яки рәсем-картина буенча хикәяләп, тасвирлап сөйләргә өйрәнү. Әсәрләрне яки өзекләрне яттан уку.

**Язу.** Матур язу күнекмәләре булдыру. Әдәби әсәр буенча куелган сорауларга кечкенә күләмле язмача җавап әзерләү (шул исәптән компьютер кулланып). Диктант, изложение язарга өйрәтү.



Әдәби әсәр эчтәлеген аңлауга мөнәсәбәтле **теоретик** төшенчәләр: әсәр темасы, төп фикере, вакыйгалары һәм аларның эзлеклелеге. Әсәр герое: герой характеры, аның эш–гамәлләре, холкы, эмоциональ һәм әхлакый кичерешләре. Табигать образы, кеше образы, хайван, кош–корт образы, сүз–сурәт. Әсәрдә сурәтләнгән дөнья: пейзаж, портрет. Автор, хикәяләүче, лирик герой. Вакыйга, күренеш, конфликт. Әдәби әсәр һәм публицистик язма, мәкалә. Фольклор жанрларын аеру: әкият, табышмак, мәкаль һәм әйтем, мәзәк, җыр. Әдәби жанрларны аеру: хикәя, шигырь, пьеса.

# 2 баскыч

**Әдәбияттан гомуми төп белем бирү (5–9 сыйныфлар) баскычының максатлары:**

- матур әдәбият әсәрләрен форма һәм эчтәлек берлегендә аңларга һәм анализларга өйрәтү;

– төп әдәби-тарихи мәгълүматларны һәм әдәби-теоретик төшенчәләрне җиткерү һәм кулланырга күнектерү;

– дөньяга гуманлы караш, гражданлык тойгысы, патриотизм хисләре, әдәбиятка һәм халыкның мәдәни кыйммәтләренә ярату һәм хөрмәт тәрбияләү;

–матур әдәбият әсәрләрен мөстәкыйль уку ихтыяҗы булдыру;

–укучыларның телдән һәм язма сөйләмнәрен үстерү.

### Әдәбияттан гомуми төп белем бирү (5–9 сыйныфлар) баскычында белем бирү эчтәлегенең мәҗбүри минимумы

Бу баскычта укыту предметы буларак матур әдәбиятның төп эчтәлеге — күпгасырлык әдәби мирасның иң камил әсәрләре, аерым язучылар иҗаты. Белем алу – аларны уку һәм өйрәнү, тикшерү–анализлау һәм нәтиҗәләр ясый, бәяли алу дигән сүз.

Уку-укыту процессында өйрәнү өчен әдәби әсәрләрне сайлап алуда төп таләп (критерий) булып аларның сәнгати кыйммәте, гуманистик эчтәлеге, укучы шәхесенә уңай йогынты ясавы, аның үсеш бурычлары һәм яшь үзенчәлекләренә туры килүе, милли рух белән сугарылуы, шулай ук мәдәни-тарихи традицияләргә һәм белем бирү тәҗрибәсенә нигезләнүе тора.

Тәкъдим ителә торган материал татар әдәбиятының үсеш-үзгәреш этапларына бәйле рәвештә бүлеп бирелә. Әдәби әсәрләр хронологик тәртиптә урнаштырыла, ә инде программа авторлары, билгеле бер максаттан чыгып, аларның урынын үзгәртә ала. Укучыларның белем һәм яшь үзенчәлекләренә бәйле әсәрләрнең күләме арту һәм әдәби процесс үзенчәлекләре белән бәйләнештә бирелүе әдәби материалның катлаулана баруына китерә[1]*.

---

[1] *Укучыларның рус телендә белем бирүче мәктәптә укулары түбәндәге үзенчәлекләргә китерә: а) зур күләмле әсәрләрне кыскартып бирү; б) татар халкының милли үзенчәлекләре, традицияләре, гореф-гадәтләре киңрәк урын алган, милләтнең рухи-мәдәни асылы тулырак чагылган

Программаларда укучыларның түбәндәге мәсьәләләрне белүе чагылыш табарга тиеш: сүз сәнгатенең образлы табигате; тәкъдим ителгән әдәби әсәрнең эчтәлеге; классик әдипләрнең тормыш һәм иҗат юлларының төп фактлары; стандартта билгеләнгән һәм программада күрсәтелгән әдәби-теоретик төшенчәләр; әдәби текстны кабул итү һәм анализлау; әдәби текстның мәгънәви өлешләрен аерып чыгару, укыган буенча тезислар һәм план төзү; әдәби әсәрнең төрен һәм жанрын ачыклау; укыган әсәрнең темасын, проблемасын, идеясен билгеләү; геройларга характеристика бирү; сюжет, композиция үзенчәлекләрен, махсус сурәтләү чараларының ролен ачу; әдәби әсәрдәге вакыйгаларны һәм геройларны чагыштыру; автор позициясен ачыклау; укыганга үзеңнең мөнәсәбәтеңне белдерү; әсәрне (өзекне) сәнгатьле итеп уку; кабатлап сөйләүнең төрләреннән файдалану; өйрәнелгән әсәргә бәйле телдән һәм язмача фикерләрне белдерү; укыган әсәр буенча фикер алышуда катнашу, фикерләреңне дәлилли белү; укыган әсәрләргә бәяләмә язу; татар әдәби теленең нормаларына нигезләнеп, кирәкле темага телдән һәм язмача бәйләнешле текст төзү; эстетик зәвыкка туры килә торган әдәби әсәрләрне сайлау һәм аларны бәяләү; аерым автор, аның әсәре, гомумән әдәбият турында кирәкле мәгълүматны белешмә әдәбият, вакытлы матбугат, Интернет чаралары һ.б. аша эзләү.

## 3 баскыч

**Әдәбияттан гомуми урта (тулы) белем бирү (9–11 сыйныфлар) баскычының максатлары:**

– татар әдәбиятының тарихи барышы турында гомуми караш булдыру;

– татар әдәбиятының барышын, аның аерым чорлардагы торышын, чор әдәбиятының йөзен билгеләүче язучылар иҗатын анализларга һәм бәяләргә өйрәтү;

–әдәби-теоретик белемнәр нигезендә әдәби әсәрнең, язучы иҗатының, чор әдәбиятының, гомумән татар әдәбиятының үзенчәлекләрен табарга күнектерү;

– иҗади фикерләүдәге уртак һәм милли үзенчәлекләрне танырга өйрәтү.

### Әдәбияттан гомуми урта (тулы) белем бирү (9–11 сыйныфлар) баскычында белем бирү эчтәлегенең мәҗбүри минимумы

Тәкъдим ителә торган әдәби әсәрләр хронологик тәртиптә урнаштырыла. Укыту укучыларның гомуми төп белемнәренә нигезләнә. Өлкән сыйныфлардагы әдәбият курсы сүз сәнгатенең тарихи үсешен системалы күзаллау булдыруга һәм шуның аша классик һәм бүгенге әдәбиятның үзара бәйләнешен тулырак аңлауга юнәлтелә. Күрсәтелгән язучылар һәм әсәрләр исемлеген программа авторлары, тирәнтен өйрәнү максатыннан чыгып, киңәйтә ала.

---

әсәрләрне анализлау; в) татар һәм рус әдәбиятларын (аерым әсәрләрен) чагыштырып өйрәнү.



Бу баскычта укыту предметы буларак матур әдәбиятның төп эчтәлеге – татар әдәбиятының барышы. Белем алу – татар әдәбиятының күпгасырлык тарихын күзаллау һәм аның аерым чорларына хас үзенчәлекләрне аерып чыгара алу, чор әдәбиятының үзенчәлекләрен һәм зур сүз осталары иҗатының яңалыгын аңлый белү. Программаларда укучыларның түбәндәге мәсьәләләрне белүе чагылыш табарга тиеш: өйрәнелгән әдәби әсәрләрне чорларның үсеш тәртибендә системалы итеп күзаллау; әдәби әсәрнең эстетик кыйммәтен, төрен һәм жанрын билгеләү; әдәби текстны анализлау; шигъри текстларны яисә чәчмә әсәрдән өзекләрне яттан өйрәнү; укучыда үз-үзен тәрбияләү күнекмәләрен булдыру; бәхәсләрдә катнашу, оппонентларның фикерен исәпкә алып, үз карашларыңны раслау һәм дәлилләү; рефератлар, докладлар әзерләү; әдәби әсәрләр һәм ирекле темалар буенча сочинениеләр язу; рус һәм татар телендәге әдәби әсәрләрне чагыштырып бәяләү, әхлакый идеалларның охшаш һәм аермалы якларын билгеләү; әдәбият теориясе, әдәбият тарихы, сәнгатьнең башка төрләре бергәлегендә укучыда әдәбиятны мөстәкыйль үзләштерерлек күнекмәләр булдыру һәм әдәбият–сәнгать белән даими кызыксыну тәрбияләү; матур әдәбиятта халык тарихы, милләт язмышы гәүдәләнешенә укучыларның игътибарын туплау; укучыларда кешелеклелек, горурлык, үз кадереңне белү хисләрен тәрбияләү.

## 2. Белем бирү нәтиҗәләренә (гомуми белем бирү программаларын үзләштерү нәтиҗәләренә) таләпләр

Белем бирү учреждениесе укучыларны һәм ата-аналарны татар әдәбиятын укыту программаларының эчтәлеге белән таныштырырга бурычлы. Программалар үтәлмәгән очракта ата-аналар (яки аларны законлы алыштыручылар) белем бирү учреждениесенә дәгъва белдерергә хокуклы.

Дәүләт аккредитациясенә ия булган башлангыч, урта һәм югары һөнәри белем бирү учреждениеләре кабул итү һәм чыгарылыш имтиханнарында бары тик стандартта каралган таләпләр генә куя ала.

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, структур (территориаль) мәгариф бүлекләре, гомуми белем бирү учреждениесе җитәкчелеге стандартны гамәлгә ашыру өчен кирәкле шартлар тудыра, белем эчтәлегенең мәҗбүри минимумын һәм чыгарылыш классы укучыларының белем дәрәҗәсенә куелган таләпләрнең үтәлешенә контрольлек итә.

Контрольлек итү мәҗбүри куела һәм түбәндәге формада үткәрелә:

- гомуми төп һәм гомуми урта (тулы) белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы гомуми белем бирү учреждениеләрендә чыгарылыш класс укучылары өчен дәүләт имтиханы;

- гомуми башлангыч, гомуми төп һәм гомуми урта (тулы) белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы гомуми белем бирү учреждениеләрен аттестацияләү һәм аккредитацияләү.

Мәктәптә татар әдәбиятын укыту укучыларга әдәби белем бирә, әдәби әсәрне, язучы иҗатын, чор әдәбиятын аңлау өчен кирәкле күнекмәләр формалаштыра, милли мәдәниятккә кагылышлы мәгълүматлар җиткерә. Шуңа күрә белем дәрәҗәсенә таләпләр һәр баскычта өч дәрәҗәгә аерып күрсәтелде.

## 1 баскыч

**Әдәбияттан гомуми башлангыч белем бирү (1–4 сыйныфлар) баскычында укучыларның белем дәрәҗәсенә таләпләр:**

- татар әдәбияты хакында гомуми мәгълүматый күзаллау булырга;
- өйрәнелгән әсәрнең исемен, төп эчтәлеген һәм авторын белергә, аңа карата үз мөнәсәбәте формалашырга;
- әсәрнең геройларын, аларның эш–гамәлләрен, холык–фигылен, хис–кичерешләр дөньясын бәяли;
- текстның сюжетын ачыклый, темасын, идеясен, автор фикерен билгели алырга;
- автор һәм хикәяләүче, шагыйрь һәм лирик герой, тезмә һәм чәчмә сөйләм, фольклор һәм әдәби жанрлар хакында күзаллый белергә;
- әдәби әсәргә һәм иҗат эшенә хас сыйфатларны һәм үзенчәлекләрне аңларга;
- әдәби тел һәм сурәтлелек тудыру чаралары хакында башлангыч күзаллау бирелергә тиеш.

**Әдәбияттан гомуми башлангыч белем бирү (1–4 сыйныфлар) баскычында формалаштырылырга тиешле күнекмәләр:**

- аңлы, дөрес һәм сәнгатьле уку күнекмәсе булдырып, бер минут эчендә кычкырып 75-80 сүзле, күңелдән – 95 сүзле текстны йөгерек укый белергә;
- тәкъдим ителгән текстка сораулар куярга;
- 1,5 биттән артык булмаган текстның эчтәлеген сөйләргә һәм кабатлап язарга;
- текстны мәгънәви бүлекләргә бүлә һәм гади план, аннотация төзи алырга;
- изложение, диктант яза алырга;
- автор текстына нигезләнгән уртача монологик сөйләм әзерли һәм әсәр геройларын, вакыйгаларын бәяли белергә;
- программада ятлау өчен тәкъдим ителгән әсәрләрнең кимендә сигезен хәтердә калдырырга;
- бирелгән темага телдән яки язмача текст әзерли алырга;
- халык авыз иҗаты әсәрләреннән мәкаль, әйтем, табышмак, әкиятләрдән мисаллар китерә белергә;
- әдәби жанрларны һәм халык авыз иҗаты жанрларын аера алырга;
- текстта махсус тел-сурәтләү чараларын: эпитет, чагыштыру, сынландыруны, шигырьдә рифманы табарга, аңлатырга.



**Әдәбияттан гомуми башлангыч белем бирү (1–4 сыйныфлар) баскычында укучыларга җиткерелә торган мәгълүматлар:**

- өйрәнелгән әсәр авторының башка әсәрләре, аның тормышы, иҗаты хакында;
- китап сайлау нечкәлекләре турында;
- төрле мәгълүмат чыганаклары (сүзлекләр, белешмәләр, электрон чаралар) белән эшләү хакында;
- балалар өчен чыга торган газета-журналлар турында.

**Әдәбияттан гомуми башлангыч белем бирү (1–4 сыйныфлар) баскычында предметара эшчәнлек:**

- әдәбиятны сәнгатьнең башка төрләре (музыка, рәсем сәнгате) белән бәйләп, аларның хыял һәм иҗат (уйлап табу) дөньясы буларак уртак якларын һәм үзенчәлекле сыйфатларын (төзү материалы, сурәтләү киңлеге) күрергә өйрәтү;
- әдәбиятны татар теле белән бәйләп, туган телнең матурлыгына һәм байлыгына хөрмәт тәрбияләү;
- татар әдәбиятын рус әдәбияты белән бәйләп, тема һәм проблематикада, геройлар бирелешендә уртаклыкларга игътибар юнәлтү.

**Әдәбияттан гомуми башлангыч белем бирү (1–4 сыйныфлар) баскычында укучыларның шәхси үсеш—үзгәреше:**

- баланың физик һәм психик сәламәтлеген саклау;
- яшь үзенчәлекләрен исәпкә алып, укучыларның уку, хезмәт, аралашу, сәнгать-матурлыкны тану күнекмәләрен үзләштерүләренә ирешү;
- укучыларда әйләнә-тирәдәге тормышка игътибар, дөрес мөнәсәбәт булдыру;
- иҗади хезмәткә теләк, кызыксыну уяту;
- укучының үзенә бәя бирә белүенә,үз-үзен тәрбияләвенә ирешү;
- яңалыкка, белемгә омтылыш формалаштыру, үстерү.

## 2 баскыч

**Әдәбияттан гомуми төп белем бирү (5–9 сыйныфлар) баскычында укучыларның белем дәрәҗәсенә таләпләр:**

- татар әдәбиятындагы аерым язучылар иҗаты, әсәрләр хакында гомуми күзаллау булырга;
- текстларны өрле яклап (тулысынча, сюжет –композиция бирелеше ягыннан, тематика–проблематика һәм образлар бирелеше аспектында, тел–стиль ноктасыннан) анализлый һәм шәрехли алырга;
- әдәби төрләр һәм жанрлар, шигырь төзелеше, тезмә һәм чәчмә сөйләм үзенчәлекләре хакында белергә;
- әдәби әсәр теориясен: әдәби образ, аның төрләре; әдәби әсәр, аның эчтәлеге һәм формасы; тема, проблема, идея; сюжет, композиция;

конфликт, аның төрләре, сәбәпләре; махсус тел – сурәтләү чаралары турында белергә;

- язучы иҗатын гомумиләштереп анализларга, бәяләргә;
- әдәбиятның тарихи барыш булуы хакында гомуми күзаллау булырга;
- әдәби әсәрнең әһәмиятен, кыйммәтен, үзенчәлекләрен аңлый һәм дәлилле итеп аңлата, исбатлый белергә тиеш.

**Әдәбияттан гомуми төп белем бирү (5–9 сыйныфлар) баскычында формалаштырылырга тиешле күнекмәләр:**

- төрле жанрдагы әдәби әсәрләрне аңлап һәм иҗади, сәнгатьле уку, аларга карата укучыларда мөстәкыйль мөнәсәбәт булдыру;
- әдәби әсәрне сюжет–композиция, образлар бирелеше, тел–стиль ягыннан анализлау;
- шигъри текстларны яисә чәчмә әсәрдән өзекләрне яттан өйрәнү;
- план төзү һәм әсәрләр турында бәяләмә, сочинение элементлары белән изложение язу;
- сайлап алып (яки тәкъдим ителгән) язучының тормыш юлын, иҗатын сөйләү;
- фольклор әсәрләренең жанрын һәм аларга хас үзенчәлекләрне тану;
- әдәби әсәрнең төрен, жанрын билгеләү һәм фикерне исбатлау;
- төрле әсәрләрнең проблемаларын яки темаларын чагыштыру, үзенчәлекләрен билгеләү;
- әдәби әсәрләр буенча һәм тормыштан алган фикер-карашларга, хис-кичерешләргә нигезләнеп сочинение язарга;
- татар, рус (яки башка халыкларның) әдәбиятларында бер төрдәге темага язылган әсәрләрне чагыштыру, милли үзенчәлекләрен ачыклау;
- рус телендәге әдәби текстларны татарчага һәм киресенчә тәрҗемә итү.

**Әдәбияттан гомуми төп белем бирү (5–9 сыйныфлар) баскычында укучыларга җиткерелә торган мәгълүматлар:**

- язучыларның тормышы, иҗаты турында (биографик);
- әдәбият тарихы, аның төрле этаплары, аерым чорларда иҗат иткән сүз осталарының иҗаты, татар әдәбиятының күренекле вәкилләре турында өстәмә;
- әдәби әсәрне, язучы иҗатын тирәнтен анализлау өчен кирәк булган өстәмә теоретик; әдәби әсәрне чор белән бәйләп характерлаучы, чорның уңай сыйфатларын, төп кыйммәтләрен табу өчен кирәкле.

**Әдәбияттан гомуми төп белем бирү (5–9 сыйныфлар) баскычында предметара эшчәнлек:**



- әдәбиятны сәнгатьнең башка төрләре (музыка, рәсем сәнгате) белән бәйләп, алар мисалында рухи байлыкның кыйммәтен, дәрәҗәсен, турлыкны таныргa өйрәтү, зәвык тәрбияләү;
- әдәбиятны татар теле белән бәйләп, татар әдәбиятының фикер көчен, хисләр байлыгын таныргa күнектерү; әдәби әсәр теленең үзенчәлекләрен, әсәр стиле, язучы стиле кебек төшенчәләрне җиткерү;
- татар әдәбиятын рус әдәбияты белән бәйләп, әдәбиятлар һәм халыклар арасындагы уртак хәзинә–рухи кыйммәтләргә хөрмәт, башка милләт - халыкларга карата түземле – ихтирамлы мөнәсәбәт (толерантлык) тәрбияләү; дөнья культурасы, кешелек тарихы төшенчәләрен үзләштерүләренә ирешү;
- әдәбиятны тарих һәм җәмгыять белеме предметлары белән бәйләп, дөнья, яшәү, кешелек җәмгыяте турында күзаллау формалаштыру.

**Әдәбияттан гомуми төп белем бирү (5–9 сыйныфлар) баскычында укучыларның шәхси үсеш—үзгәреше:**

- укучының активлыгын, мөстәкыйль фикерләвен, акыл һәм рухи эшчәнлеген активлаштыру, өйрәтү, шәхес буларак формалаштыру;
- укучыны үзен тәрбияләргә, үзе белән идарә итәргә, алган белем һәм күнекмәләрен тормышта куллана белергә, тормышта үз урынын сайларга әзерләү;
- баланың үзаңын үстерү, милләтне, ватанны яратырга өйрәтү, горурлык һәм гражданлык хисләре тәрбияләү;
- әхлак (этик) нормаларын, җәмгыятьтә яшәү кагыйдәләрен төшендерү.

## 3 баскыч

**Әдәбияттан гомуми урта (тулы) белем бирү (9–11 сыйныфлар) баскычында укучыларның белем дәрәҗәсенә таләпләр:**

- әдәби-тарихи процессның төп закончалыкларын, этапларын, чор әдәбиятына зур өлеш керткән әдипләр иҗатын белергә;
- мәктәп курсында өйрәнелгән әсәрләрне чорларның үсеш тәртибендә өзлексез барыш итеп күзалларга;
- әдәбият тарихы һәм теориясе буенча белемнәргә (тема, проблема, идея, пафос, образлар системасы, сюжет-композиция, телнең сәнгати сурәтләү чаралары, әдәби деталь) нигезләнеп, әдәби әсәрне анализларга һәм шәрехләргә;
- әсәрне чорга хас әдәби юнәлеш белән бәйлелектә тикшерергә, аңлатырга;
- классик әдипләрнең тормыш һәм иҗат юлларының төп фактларын белергә;
- әдәбият теориясенә караган иң әһәмиятле төшенчәләрне, аларның билгеләмәләрен белергә (әдәби процесс, иҗат методы, сәнгатьчә алымнар – чаралар, анализ төрләре, язучының стиле, әдәбият һәм чор, шәхес һәм җәмгыять бәйләнешләре);

- татар әдәбиятында традицияләр һәм яңару процессы, жанрлар үсеше турында гомуми күзаллау булырга тиеш.

**Әдәбияттан гомуми урта (тулы) белем бирү (9–11 сыйныфлар) баскычында формалаштырылырга тиешле күнекмәләр:**

- әдәби әсәрне иҗтимагый һәм мәдәни тормыш күренешләре белән бәйлелектә аңлау;
- изложение һәм өйрәнелгән әсәрләр буенча яки бирелгән темага сочинение язу;
- тәкъдим ителгән яки укучы үзе сайлаган әсәрләрне (шигырь, проза) яттан сөйләү;
- язучыларның иҗатларын, әсәрләрен чагыштырып уртак һәм аермалы якларын аңлата, бәяли белү;
- әдәби сурәт чараларын тиешенчә кулланып, татар әдәби текстларын рус теленә һәм киресенчә тәрҗемә итү;
- татар һәм рус телендәге әсәрләргә телдән һәм язмача фикереңне белдерү, аларга бәя бирү.

**Әдәбияттан гомуми урта (тулы) белем бирү (9–11 сыйныфлар) баскычында укучыларга житкерелә торган мәгълүматлар:**

- әдәби әсәрләрнең тарихи-конкрет һәм гомумкешелек кыйммәтләрен ачу өчен кирәкле;
- әдәбияттагы «үтәли» һәм «мәңгелек» проблемаларны ачыклый торган;
- сүз сәнгатенең аерым күренешләре белән мөстәкыйль танышу һәм аларның эстетик кыйммәтен бәяләү өчен кирәкле;
- татар әдәбиятының рус һәм дөнья әдәбияты мәйданындагы урынын һәм ролен бәяләргә ярдәм итүче.

**Әдәбияттан гомуми урта (тулы) белем бирү (9–11 сыйныфлар) баскычында предметара эшчәнлек:**

- сәнгатьнең башка төрләре ярдәмендә укучыда әдәбиятны мөстәкыйль үзләштерерлек күнекмәләр булдыру һәм әдәбият–сәнгать белән даими кызыксыну тәрбияләү, әдәбиятның сәнгать төре буларак үзенчәлекләрен тулырак ачыклау;
- әдәбиятны татар теле белән бәйләп, чор әдәбияты стиле, иҗат юнәлешләре стиле, язучы стиле кебек төшенчәләрне җиткерү;
- татар әдәбиятын рус әдәбияты белән бәйләп, әдәби әсәрне, язучы иҗатын, чор әдәбиятын анализларга күнектерү; татар әдәбиятының рус һәм дөнья әдәбиятлары мәйданындагы урынын, дәрәҗәсен билгеләү;
- әдәбиятны тарих һәм җәмгыять белеме предметлары белән бәйләп, әдәбиятны чорларның үсеш тәртибендә системалы итеп күзаллау формалаштыру.



**Әдәбияттан гомуми урта (тулы) белем бирү (9–11 сыйныфлар) баскычында укучыларның шәхси үсеш—үзгәреше:**

- укучының мөстәкыйль фикерләвен, гомумиләштереп нәтиҗәләр ясау сәләтен үстерү;
- матур әдәбиятта халык тарихы, милләт язмышы гәүдәләнешенә укучыларның игътибарын туплау; укучыларда кешелеклелек, горурлык, үз кадереңне белү хисләрен тәрбияләү;
- укучыда мәктәпне тәмамлап чыккач та матур әдәбият укуга ихтыяҗ булдыру;
- әдәби әсәрнең эстетик кыйммәтен, поэтикасын аңларлык эстетик зәвык булдыру.

## 3. Гомуми белем бирүнең эчтәлеге (фундаменталь төш)

### Гомуми башлангыч белем бирү мәктәбе (1 нче баскыч – I–IV сыйныфлар)

**Халык иҗат иткән әкиятләр**: «Өч кыз», «Зөһрә кыз», «Наян төлке», «Камыр батыр». «Сак–Сок» бәете*[1].
Җ.Тәрҗеманов. «Тукран малае Шуктуган» әкияте.
Дәрдемәнд хикәятләре*: «Кояш нурлары», «Богдай», «Гали».
А.Алиш әкиятләре: «Сертотмас үрдәк», «Нечкәбил», «Чукмар белән Тукмар».
Г.Сабитов хикәяләре: «Чүкеч», «Тәүге соклану»*, «Тәүге шатлык»*, «Тәүге батырлык»*.
Ф.Яруллин шигырьләре: «Гайни», «Туган ягы кирәк кешегә».
Н.Әхмәдиев. «Ана»*, «Тәрбияле малай» хикәяләре.
Г.Тукай шигырьләре: «Туган тел», «Сабыйга»*, «Җир йокысы»*, «Бәхетле бала»*, «Эш». «Су анасы»*, «Шүрәле»* поэмалары. «Исемдә калганнар»* автобиографик хикәясе.
М.Гафури. «Тавык белән үрдәк» мәсәле*.
Һ.Такташ шигырьләре: «Тәүфыйклы песи», «Пи–би–бип», «Урман»*.
Б.Рәхмәт шигырьләре*: «Чүлмәк башлы кәҗә», «Кыш һәм кеше», «Кошлар киткәндә».
М.Җәлил шигырьләре: «Карак песи», «Яз»*.
Н.Исәнбәт. «Мыраубай батыр» әкиятеннән өзекләр*.
Х.Туфан. «Туган тел» шигыре.
З.Туфайлова. «Әни сүзе» шигыре.
Ә Бикчәнтәева шигырьләре: «Каз бәбкәләре», «Дәү әнием», «Җил сөйләшә беләме?».
Зыя Мансур шигырьләре: «Кырмыска», «Озын колак баласы елак–мылак»*.
Хәй Вахит. «Наратлыдан Каенсарга...» шигыре.
С.Сөләйманова. «Кем уяткан Ләйләне» шигыре.

[1] *Йолдызчык белән бирелгән әсәрләр татар мәктәбе өчен генә мәҗбүри тәкъдим ителә.

Ш.Галиев шигырьләре: «Витаминлы хәрефләр»*, «Мактаныша малайлар», «Онытылган», «Борау»*, «Пәрәмәч»*, «Рәхмәтләр хакында».
Р.Миңнуллин шигырьләре: «Югалган көн», «Саный беләм», «Дөньядагы иң зур алма»*.
Н. Фәттах. «Энҗеле үрдәк» драмасы*.
Т.Миңнуллин. «Кәрлә — мәктәп баласы» комедиясе.

**Гомуми төп белем бирү мәктәбе (2 нче баскыч – V–IX сыйныфлар)**

Халык авыз иҗаты

Риваятьләр һәм легендалар. «Иске Казан каласы корылуы»*, «Шәһәр ни өчен Казан дип аталган», «Елан тавы»* риваятьләре; «Зөһрә кыз», «Кеше гомере ничек корылган»* легендалары.

Җырлар: «Болгар иленең кызлары»*. «Пугач явы»*. «Иске кара урман». «Гөлҗамал». Кыска җырлар.

Әкиятләр: «Ак бүре»*. «Таң батыр»*. «Серле балдак». «Кәҗә белән сарык».

Хуҗа Насретдин турындагы мәзәкләр.

Мифлар: «Су иясе»*. «Алып кешеләр».

Дастаннар: «Идегәй»*.

Борынгы һәм Урта гасыр әдәбияты

Кол Гали. «Кыйссаи-Йосыф».
С.Сараи. «Сөһәйл вә Гөлдерсен».

XIX йөз татар әдәбияты

Г.Кандалый шигырьләре: «Иген икмәк бирер икмәк». «Бу бала хәсрәте түкде...», «Бу хәсрәтләр бетәр микән?».
К.Насыйри. «Әбүгалисина» повесте.
М.Акъегет. «Хисаметдин менла» повесте.
З.Бигиев. «Өлүф, яки Гүзәл кыз Хәдичә» романы*.
Ф.Халиди. «Рәдде Бичара кыз» драмасы*.
Р.Фәхретдин. «Әсма, яки Гамәл вә җәза» повесте* (өзекләр).

XX йөз башы әдәбияты

Ф.Әмирхан. «Хәят» повесте. «Бер хәрабәдә» хикәясе.
Дәрдемәнд шигырьләре: «Каләмгә хитап»*, «Замана»*, «Видагъ», «Җәй үтте...».
Г. Ибраһимов хикәяләре: «Яз башы».
Г. Исхакый. «Сөннәтче бабай»*, «Кәҗүл читек» хикәяләре. «Алдым–бирдем» комедиясе*.
Г.Камал «Беренче театр» комедиясе.
Ш.Камал «Буранда» хикәясе. «Акчарлаклар» повесте*.
С.Рәмиев шигырьләре: «Таң вакыты», «Сызла, күңелем», «Авыл»*.



Г.Тукай шигырьләре: «И каләм!», «Туган авыл», «Пар ат», «Туган җиремә», «Милли моңнар», «Кичке азан»*, «Ана догасы»*, «Шагыйрь»*.
М.Гафури. «Сарыкны кем ашаган?» мәсәлә.

**XX йөз әдәбияты**

*1920-30 еллар*

Ф. Бурнаш. «Таһир-Зөһрә» шигъри трагедиясе.
Г. Ибраһимов. «Алмачуар» хикәясе. «Кызыл чәчәкләр» повесте*.
Г.Кутуй.«Тапшырылмаган хатлар» повесте.
Һ.Такташ шигырьләре: «Зәңгәр күзләр»*, «Алсу», «Болай …гади җыр гына», «Мокамай».
К.Тинчурин. «Сүнгән йолдызлар» драмасы.
Г.Исхакый. «Җан Баевич» комедиясе.

*Ватан сугышы чоры әдәбияты*

Г.Кутуй. «Сагыну» нәсере.
Ф.Кәрим шигырьләре: «Үлем уены», «Кыр казы»*, «Сибәли дә сибәли», «Сөйләр сүзләр бик күп алар».
М.Җәлил шигырьләре: «Җырларым», «Тик булса иде ирек», «Кызыл ромашка». «Сандугач һәм чишмә» балладасы*.

*Сугыштан соңгы чор һәм хәзерге әдәбият*

Х.Туфан шигырьләре: «Гөлләр инде яфрак яралар», «Киек казлар», «Чәчәкләр китерегез Тукайга»*, «Кайсыгызның кулы җылы», «Илдә ниләр бар икән».
С.Хәким шигырьләре: «Әнкәй», «Һәйкәл урынында уйланулар», «Колын».
Ә.Еники хикәяләре: «Әйтелмәгән васыять», «Кем җырлады?», «Туган туфрак», «Матурлык»*.
Ф.Яруллин. «Җилкәннәр җилдә сынала» повесте*, «Сез иң гүзәл кеше икәнсез» шигыре.
М.Әгъләмов шигырьләре: «Китә алмыйм...», «Учак урыннары», «Каеннар булсаң иде».
А.Гыйләҗев. «Җомга көн кич белән» повесте*.
М.Мәһдиев. «Кеше китә — җыры кала» повесте.
Т.Миңнуллин. «Әлдермештән Әлмәндәр» драмасы.
Р.Фәйзуллин. «Җаныңның ваклыгын сылтама заманга...»*, «Вакыт»*, «Якты моң». Кыска шигырьләр.
Н. Фәттах. «Ител суы ака торур» романы*.
И.Юзеев. «Бакчачы турында баллада» балладасы. Шигырьләре: «Сагышлы мирас», «Гасыр кичкән чакта...», «Без». «Өчәү чыктык ерак юлга» поэмасы*.
Ф.Садриев. «Таң җиле» романы*, «Кыргый алма әчесе» повесте.
М.Галиев. «Алтын тотка» повесте.

**Төп әдәби-теоретик төшенчәләр**

Сүз сәнгате буларак әдәбият. Язма әдәбият һәм фольклор. Халык авыз иҗаты жанрлары. Әдәби төрләр һәм жанрлар. Образлар системасы. Автор образы, хикәяләүче образы; лирик герой.

Әдәби әсәрнең формасы һәм эчтәлеге: тема, проблема, идея, сюжет, композиция; сюжет элементлары; конфликт. Әдәби әсәрнең теле. Әдәби сурәтләү чаралары: чагыштыру, эпитет, метафора, гипербола, метонимия, символ, аллегория, җанландыру. Пейзаж. Портрет. Юмор һәм сатира.

Шигырь төзелеше: ритм, рифма, строфа.

Әдәбият тарихы. Әдәби процесс. Әдәби юнәлешләр һәм агымнар. Матур әдәбиятта гомумкешелек кыйммәтләре һәм әсәрнең милли үзенчәлеге.

**Төп әдәби-тарихи мәгълүматлар**

Тормышны танып белүнең бер формасы һәм кеше рухи дөньясының байлыгын, күптөрлелеген чагылдыручы буларак матур әдәбият. Әдәбият һәм сәнгатьнең башка төрләре. Сүз сәнгате (әхлаклылык, миһербанлылык тәрбияләү, яшәүнең төп принципларын, дөньяга дөрес караш, эстетик зәвык формалаштыру һәм, гомумән, гомумкешелек кыйммәтләре белән таныштыру).

Матур әдәбиятның иҗтимагый һәм мәдәни тормыштагы урыны. Татар әдәбиятының милли үзенчәлеге, гуманистик эчтәлеге, традицияләр дәвамчанлыгы һәм яңачалык. Татар әдәбияты мөрәҗәгать иткән тема-мотивлар, гомумкешелек кыйммәтләре.

Әдәбиятның формалашуы, шартлары, сәбәпләре. Әдәбиятны чорларга бүлүнең закончалыклары. Әдәбиятның үсешендә тотрыклы сыйфатлар – традицияләр саклану; үсеш – яңарыш, новаторлык. Әдәбиятны алга үстерүче сәбәпләр.

Халык авыз иҗаты

Халыкның милли рухи культура хәзинәсе буларак халык авыз иҗаты. Фольклор әсәрләрендә гомумкешелек кыйммәтләренең зур урын тотуы. Халык иҗатының язма әдәбият үсешенә, әдәби телгә зур йогынты ясавы. Фольклорның төп жанрлары: әкиятләр, мәкаль һәм әйтемнәр, табышмаклар, җырлар, бәетләр, риваятьләр һәм легендалар, дастаннар.

Борынгы һәм Урта гасыр татар әдәбияты

Борынгы һәм Урта гасыр әдәбиятының мифологиягә һәм халык авыз иҗатына нигезләнүе. Ислам дине идеологиясе белән сугарылуы. Шәрык әдәбиятлары йогынтысы. Күчмә сюжетлар. Әсәрләрнең тематик төрлелеге һәм проблематикасы: гадел хөкемдар, кеше һәм Алла, шәхес һәм җәмгыять мөнәсәбәте, илаһи мәхәббәт һәм җир мәхәббәте, гаделлек, миһербанлылык, сабырлык . Әдәбиятта дини-әхлакый, суфыйчыл һәм дөньяви карашларның үрелеп баруы. Жанрлар төрлелеге.

XIX йөз әдәбияты

Бер яктан, урта гасыр әдәбияты традицияләренә нигезләнүе, икенче яктан, җәмгыятьтәге үзгәрешләргә бәйле яңа сыйфатлар белән баюы: реализм юлына чыгу, яңа төрләр һәм жанрлар барлыкка килү, сурәтләүнең яңа алым-чараларына мөрәҗәгать итү. Мәгърифәтчелек чоры әдәбиятының үзенчәлекләре. Һәртөр искелеккә каршы көрәшеп, идеал кеше образы



тудырылу. Әдәбиятның чынбарлык проблемаларына мөрәҗәгать итүе. Яңа заман сүз сәнгатенә нигез салыну. Әдәбиятның мәгариф һәм мәдәният үсеше белән бәйләнеше. Жанрлар үсеше, иҗат методларының (юнәлешләренең) ачыклана баруы. Прозаның мөстәкыйль төр булып формалашуы. Драматургиянең беренче үрнәкләре.

XX гасыр башы татар әдәбияты

Татар иҗтимагый тормышында һәм әдәбият үсешендә иң бай, катлаулы вакыйгалар чоры. Милли азатлык хәрәкәте, 1905-07 еллар инкыйлабы тудырган шартларда матбугат, әдәбият һәм сәнгатьнең күтәрелеше; драматургиянең, татар театрының үсүе; яңа жанр һәм стильләр. Татар сүз сәнгатенең Шәрык һәм рус-Европа әдәби-фәлсәфи, мәдәни казанышларын үзләштерүе. Милләт проблемасының үзәккә куелуы. Әдәбиятның реалистик һәм романтик чагылдыру үзенчәлекләре. Әхлакый һәм фәлсәфи эзләнүләр. Яңарыш чоры әдәбиятының әһәмияте.

XX гасыр татар әдәбияты

Совет чоры татар әдәбиятының каршылыклы үсеше. Төп тема-проблемалар. Әдип һәм җәмгыять мөнәсәбәте. Бөек Ватан сугышы һәм татар әдәбияты. Илленче еллар ахырыннан башлап әдәбиятта сыйфат үзгәрешләре башлану. Сүз сәнгатендә милләт проблемасының алгы планга чыгуы. Әдипләрнең заман сорауларына актив мөрәҗәгать итүе. Җәмгыятьтәге үзгәрешләрнең әдәбиятта чагылышы.

Совет чоры әдәбиятында революцион вакыйгаларның әдәбиятка йогынтысы һәм әдәбиятта чагылышы. Традицияләрнең яңаруы, яңа җәмгыять сыйфатларын эзләү, яңа герой образы. Ватан, ил, халык образларының эпик гәүдәләнеше; шәхес һәм җәмгыять мөнәсәбәтләре, гражданлык хисе, халыклар язмышы, кешенең рухи дөньясы, чор кыйммәтләре турында уйлану. Азатлык, шәхес иреге, фикер хөрлеге мәсьәләләренең куелышы. Дөнья әдәбияты белән бәйләнеш, бүгенге көн әдәбиятында яңарыш.

**Гомуми урта (тулы) белем бирү мәктәбе (3 нче баскыч – X–XI сыйныфлар)**

*Борынгы татар әдәбияты (5—12 гас.)*

*Гомумтөрки әдәбият*. Орхон–Енисей ташъязмалары.

*Урта гасыр әдәбияты*

*Болгар чоры мәдәнияте* (12—13 гас. 1 яртысы). Кол Гали. «Кыйссаи – Йосыф» поэмасы.

*Алтын Урда чоры мәдәнияте* (13—15 гас. 1 яртысы). С.Сараи. «Гөлестан бит төрки» поэмасы. Котб. «Хөсрәү вә Ширин» поэмасы*.

*Казан ханлыгы чоры мәдәнияте* (15 гас.1 яртысы—16 гас.2 яртысы). Кол Шәриф шигырьләре*: «Иңнек...», «Башкүтәр гафилдин». Мөхәммәдьяр. «Нәсыйхәт» шигыре, «Нуры содур» поэмасы*.

*Торгынлык чоры мәдәнияте* (16 гас.2 яртысы—19 гас.1яртысы). М.Колый. Хикмәтләр: «Юмартлык бу күңелне рушан кылыр...», «Игенчелек гали эшдер...»*, «Гыйлемлек хак рәхәттер...»*.

Г.У. Имәни. «Мәрсия Хәмидә зәүҗәте Габдерәхим Болгари» шигыре*. «Мөһимматез—заман» поэмасыннан «Йегет булмакның бәяны» бүлеге*.

*Яңарыш чоры әдәбияты*

*XIX йөз мәдәнияте. Г.Кандалый.* «Йакутлар табыладыр вакыт берлән...», «Бу илләрдә торып калсам...» шигырьләре, «Сәхибҗамал» поэмасы*.

Акмулла шигырьләре: «Башка милләт алга таба барыр булды...», «Сүз чыгар шагыйрьләрдән хикмәт белән». «Дамелла Шиһабеддин хәзрәтнең мәрсиясе» поэмасыннан өзек.

Ф.Кәрими. «Морза кызы Фатыйма» повесте.

*XX йөз башы* мәдәнияте .Г.Ибраһимов. «Яшь йөрәкләр» романы.«Татар шагыйрьләре» китабы*.

Г.Исхакый. «Көз», «Ике йөз елдан соң инкыйраз»*, «Остазбикә»*, «Ул әле өйләнмәгән иде» повестьлары.

Г.Тукай шигырьләре: «Үтенеч»*, «Күңел», «Аң»*, «Өзелгән өмид», «Мәхәббәт», «Кыйтга», «Бәйрәм вә сабыйлык вакыты»*. «Печән базары, яхуд Яңа Кисекбаш»*.

С.Рәмиев шигырьләре: «Җәмилә»*. «Сүзем һәм үзем»*. «Пәйгамбәр».

Дәрдемәнд шигырьләре: «Кораб», «Гөрләгән сулар башында», «Бүзләрем маналмадым»*, «Без», «Сеңеп җиргә...»*, «Куанды ил»*.

Г.Камал. «Банкрот» комедиясе*.

Ф.Әмирхан. «Фәтхулла хәзрәт» повесте*. «Шәфигулла агай» хикәясе.

М. Фәйзи драмалары: «Галиябану», «Ак калфак»*.

Г.Колахмәтов. «Ике фикер» драмасы*.

*XX гасыр әдәбияты*

*20–30 еллар мәдәнияте.* М.Галәү. «Болганчык еллар» романы*.

К.Тинчурин. «Американ» комедиясе.

Г.Рәхим. «Идел» повесте*.

Һ.Такташ. «Мәхәббәт тәүбәсе» поэмасы. «Җир уллары» трагедиясе.

*Сугыш чоры мәдәнияте.* М.Җәлил. «Моабит дәфтәрләре» циклы.

Ә.Еники. «Ана һәм кыз», «Бер генә сәгатькә» хикәяләре.

Ф.Хөсни «Йөзек кашы» повесте.

*Сугыштан соңгы чор мәдәнияте (50–60 еллар).* Х.Туфан шигырьләре: «Ә үткәнгә хатлар бармыйлар»*, «Агыла да болыт агыла», «Иртә төшкән кар»*, «Сиңа».

Х.Вахит «Беренче мәхәббәт» драмасы.

*1960–80 еллар мәдәнияте.* Ә.Еники. «Гөләндәм туташ хатирәсе» повесте. «Төнге тамчылар» хикәясе*, «Тынычлану» повесте*.

С.Хәким шигырьләре: «Башка берни дә кирәкми», «Сусау».

А.Гыйләҗев. «Өч аршын җир» повесте.

Ш.Хөсәенов. «Әни килде» драмасы.

1980–2000 еллар *мәдәнияте.* И.Салахов. «Колыма хикәяләре» романы.

Ф.Бәйрәмова. «Болын» повесте*.



М.Хәбибуллин. «Кубрат хан» романы.

Т.Миңнуллин. «Эзләдем, бәгърем, сине» драмасы.

И.Юзеев. «Гашыйклар тавы» поэмасы.

Гамил Афзал шигырьләре: «Язмышлар», «Елмаям уйчан гына»*, «Бигрәк юаш басып йөрдем җиргә», «Чабаклар йөзгән Иделдә»*.

Р.Фәйзуллин. «Нюанслар илендә» циклы.

Зөлфәт шигырьләре: «Баш очында...», «Дүрт җыр», «Тамыр көлләре»*, «Тойгыларда алтын яфрак шавы»*.

*2000—2008 еллар мәдәнияте.* М.Кәбиров. «Мәхәббәттән җырлар кала» повесте*.

З.Хәким. «Бит» драмасы.

Р.Зәйдулла шигырьләре: «Без очарга әзерләнгән идек...»*, «Соңару», «Буран».

**Төп әдәби-теоретик төшенчәләр**

Әдәбият тарихы. Әдәби юнәлешләр һәм агымнар: реализм (мәгърифәтчелек, тәнкыйди, социалистик реализм), романтизм, модернизм (символизм, имажинизм, футуризм һ.б.).

Әдәби барыш. Традицияләр. Яңачалык. Дәвамчанлык. Халыкчанлык. Тарихилык. Миллилек.

Әдәби төрләр (эпос, лирика, драма) һәм жанрлар: роман, повесть, хикәя, очерк, нәсер, поэма, баллада, күңел лирикасы, фәлсәфи лирика, гражданлык лирикасы, комедия, трагедия, драма.

Әдәби әсәр: тематика һәм проблематика, сюжет, композиция. Образлар системасы. Персонаж. Характер. Тип. Лирик герой.

Әсәрдә сурәтләнгән дөнья: портрет, пейзаж, психологизм, деталь. Юмор һәм сатира.

Әсәр теле. Сурәтләү чаралары. Стиль. Шигырь төзелеше. Әдәби тәнкыйть.

**Төп әдәби-тарихи мәгълүматлар**

Борынгы, Урта гасыр һәм XIX йөз әдәбияты.

Бу чорлар әдәбиятында төп тема һәм мотивлар (гуманлылык, әхлакый сафлык, мәхәббәт, кешенең бәхеткә хокукы, сабырлык, изгелек). Әдәбият үсешендәге төп юнәлешләр (яңарыш, дини-әхлакый, суфичыл). Әдәбиятның милли үзенчәлеге. Шәрык әдәбияты йогынтысы. Сүз сәнгатенең ислам дине идеологиясенә нигезләнүе. Үзәктә Алла һәм Кеше мөнәсәбәте тору. Сурәтләүдә Урта гасыр романтизмы өстенлек итү, аның төп сыйфатлары. Жанрлар төрлелеге.

Тормыш-чынбарлыкны әдәби күзаллауның яңа баскычы буларак XIX йөз урталарында реализм мәйданга чыгу. Кеше шәхесенә игътибар арту, аның милләт язмышы белән кушылып китүе. Әдәбиятның мәгърифәтчелек идеяләрен нигез итеп алуы. Яңа төрләр һәм жанрлар барлыкка килү. Рухи дөньясы һәм тышкы кыяфәте матур булган идеал кеше образы тудырылу. Әдәбиятта алгы планга дини һәм дөньяви белем системасын камилләштерү, әхлакый сыйфатлар тәрбияләү, хатын-кыз язмышы, шәхескә мохит

йогынтысы, искелек һәм яңалык күрәше, алдынгы халыклар мәдәниятен үзләштерү кебек мәсьәләләр чыгу. Дөньяви проблемаларның дини карашлар белән кушылып китүе.

XX йөз татар әдәбияты

Татар әдәбиятының Яңарыш чорына керүе. Чынбарлыкны реалистик һәм романтик сурәтләү алымнары ярдәмендә чагылдыру. Яңа әдәби агымнар эзләү. Тарихи-иҗтимагый, мәдәни вакыйгалар (инкыйлаблар, гражданнар сугышы, күмәк хуҗалыклар төзү, репрессияләр, ике тапкыр алфавит алышыну) һәм аларның әдәбиятка йогынтысы. 20-30 нчы елларда әдәбиятның каршылыклы үсеше. Вульгар социологизм күренеше. Төп иҗат методы буларак социалистик реализмның кабул ителүе. Бөек Ватан сугышы һәм аның әдәбиятта чагылышы. «Хрущев җепшеклеге»нең сүз сәнгатенә уңай йогынтысы. Сәнгати эзләнүләрнең киңәюенә, тема-мотивларның, жанрларның төрлелегенә омтылу. Идеологик таләпләргә буйсындырылган официаль юнәлеш белән янәшә милләт язмышын үзәккә куйган гуманистик эчтәлекле әдәбиятның үсеш-үзгәреш кичерүе.

**Стандарт түбәндәге авторлар төзегән беренче буын стандартларга нигезләнеп эшләнде:**

| | |
|---|---|
| Ф.Х.Завгарова | КДУның хәзерге татар әдәбияты һәм укыту методикасы кафедрасы доценты, фил.фән.канд. |
| Ә.М.Закирҗанов | КДУның татар әдәбияты кафедрасы доценты, пед.фән.канд. |
| Ф.Ф. Хәсәнова | ТДГПУның татар әдәбияты кафедрасы доценты, фил.фән.канд. |
| И.К. Тимершина | Казан шәһәре 77 урта мәктәбенең югары категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы |
| Җ.Х. Йосыпова | Чаллы шәһәре 57 урта мәктәбенең югары категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы |

| | |
|---|---|
| Ф.Ә.Ганиева | ТДГПУның әдәбият белеме кафедрасы проф., фил. фән. канд. |
| А.Г. Яхин | КДУның хәзерге татар әдәбияты һәм укыту методикасы кафедрасы доценты, фил.фән.канд. |
| Л.Г. Әминова | Актаныш районы 1 нче урта мәктәбенең югары категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы |